**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы**
**КАРАРЫ**

**2018 елның «12» апреленнән** **№ 35-201**

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2017 елның 30 октябрендәге 30-175 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә»гә үзгәрешләр кертү хакында»**

«Татарстан Республикасы кодексына муниципаль хезмәт турында үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 14 декабрендәге 90-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәнең 7 бүлегенең «Муниципаль хезмәт, класслы чиннар вазыйфаларын биләү өчен квалификация таләпләре» исемле 7.2 статьясын түбәндәге эчтәлекле искәрмә белән тулыландырырга:

«Искәрмә. 2020 елның 1 октябренә кадәр авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (секретаре) вазыйфасын биләү өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә квалификация таләпләре урта һөнәри белеме булуны күздә тота».

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәнең 7 бүлегенең «Муниципаль хезмәт, класслы чиннар вазыйфаларын биләү өчен квалификация таләпләре» исемле 7.3 статьясын түбәндәге эчтәлекле искәрмә белән тулыландырырга:

«Искәрмә. 2020 елның 1 октябренә кадәр авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (секретаре) вазыйфасын биләү өчен белгечлек буенча эш стажына квалификация таләпләре белгечлек буенча кимендә ике ел яки кимендә өч ел стажын күздә тота».

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru", «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башлыгы** **В. М. Козлов**